Утверждено
приказом Министерства
образования и науки
Республики Татарстан
от «____»________2016 г.
№ ________________

XIV республикакүләм Ризаэддин Фәхреддин укуларының
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## I. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге нигезләмә XIV республикакүләм Ризаэддин Фәхреддин укуларын үткәрү тәртибен билгели.

1.2. XIV республикакүләм Ризаэддин Фәхреддин укулары (алга таба — Укулар) Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы планы нигезендә үткәрелә.

## II. Укуларның максаты

Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту процессында куллану тәҗрибәсе белән уртаклашу, бөек шәхес үрнәгендә туган халкыңа, милләтеңә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү үзенчәлекләрен өйрәнү.

## III. Укуларны оештыручылар

Укуларны оештыручылар:

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы

Татарстан Республикасы язучылар берлеге

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре башкарма комитеты мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе

Яр Чаллы педагогия университеты

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»

## IV. Укуларда катнашучылар

Укуларда гомуми белем бирү учреждениеләренең татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучылары, музей җитәкчеләре, тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары катнаша ала.

## V. Укуларның эш юнәлешләре

«Үткәнен белмәгән кешенең киләчәге юк» (Тарих бүлеге)

Р.Фәхреддин мирасы һәм хәзерге заман. (Бүгенге көн әдәбият сулышы)

«Гыйлемнән башка байлык, байлыктан башка гыйлем булмас». (Татар мәгърифәтчеләре хезмәтләрен өйрәнү)
«Игелек орлыклары чәчегез, бәхет игеннәре игәрсез». (Тәрбия өлкәсендә Р.Фәхреддин хезмәтләре).

## VI. Фәнни- гамәли эшләргә таләпләр

6.1. Фәнни-гамәли эшләр, фәнни-эзләнү эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

эш һәр яктан 2 см поля калдырып, Microsoft Word форматында, Times New Roman шрифты белән, 14 нче кегль, 1,5 ара (интервал) аша бит киңлеге буенча тигезләп, 1,25 мм кызыл юл калдырып, сүзләрне юлдан-юлга күчермичә, компьютерда җыелырга тиеш. Сылтамалар текст эчендә шакмак җәяләрдә китерелә [1:182]. Кулланылган әдәбият исемлеге текст азагында алфавит тәртибендә бирелә.

6.2. Текст түбәндәге кагыйдәләрне истә тотып җыелырга тиеш:

абзацтагы сүзләр бер генә ара (пробел) аша язылырга тиеш;

тыныш билгеләре алдыннан ара (пробел) калдырылмый, тыныш билгесеннән соң бер ара (пробел) калдырыла;

дефис (озын сызык) һәм сызыкча (кыска сызык) аерылырга тиеш.

6.3. Укуларга башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

6.4. Педагогик укуларга материаллар татар телендә кабул ителә.

6.5. Күрсәтелгән вакыттан соңрак җибәрелгән яки куелган таләпләргә җавап бирмәгән эшләр кабул ителми.

## VII. Укуларны үткәрү тәртибе

7.1. Укулар түбәндә күрсәтелгән вакыт кысаларында үтә:

Заявка, фәнни-гамәли эшләр, фәнни-эзләнү эшләре 2017 елның 13 нче гыйнварына кадәр sch52_chelny@mail.ru электрон адресына җибәрелә. Элемтә өчен телефон — 8(8552)59-36-88.

Укулар 2017 нче елның 27 нче гыйнварында Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» бинасында үткәрелә. Адресы: 423727, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре, Автомобиль төзүчеләр урамы, 5 нче йорт.

Электрон адрес: sch52_chelny@mail.ru

Элемтәгә керү өчен кирәкле телефон: 8-917-298-88-45, Дания Васил кызы Багаутдинова.

Укуларда чыгыш ясау вакыты - 7 минутка кадәр. Катнашучы бирелгән вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерләрен күрсәтеп бирә белергә тиеш. Компьютер презентациясе, мультимедия технологияләрен куллану хуплана.

7.2. Укуларда катнашу өчен гариза түбәндәге формада җибәрелә:

| |
|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча) |
| Эш урыны, вазифасы |
| Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме |
| Адресы |
| Телефоны |
| E-mail |
| Эшнең темасы |
| Техник чаралар кирәк булачакмы? |

VIII. Укуларны йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Укуларда катнашучыларның фәнни-гамәли эшләрен һәм чыгышларын Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы приказы белән расланган жюри бәяли.

Укуларда җиңүчеләргә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы дипломнары тапшырыла, катнашучыларга шәһадәтнамә тапшырыла.

Белешмәләр өчен телефоннар:

8 (8552) 30-57-35, 30-57-24 (Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре башкарма комитеты мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе);

8 (8552) 59-36-88 (Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»).

Электрон почта: sch52_chelny@mail.ru

Материалны калыпка салу үрнәге

Сәләхова М.Р.
Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет
гомуми белем бирү учреждениесе
«52 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»

## РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ ПЕДАГОГИК МИРАСЫ

Текст

Әдәбият

1. Миңнегулов Х. Гасырлар өнен тыңлап.../ Х.Миңнегулов.-Казан:Мәгариф 2003.-336 б.
2. Ризаэддин Фәхреддин: тормыш юлы. Иҗади мирасы: Дәреслек-хрестоматия/Төз.:Р.Ш.Шаһиев.-Казан:РИЦ “Школа”, 2005.-272 б.